КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 5 март г.Казань № 175

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 28 июнь, 476 нчы карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы территориясендә «Туризмны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе территориясе буенча туристлык сәяхәтләре саны» күрсәткеченә ирешү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы территориясендә «Туризмны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе территориясе буенча туристлык сәяхәтләре саны» күрсәткеченә ирешү белән бәйле аларның чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 28 июнь, 476 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 25 октябрь, 925 нче; 2025 ел, 20 август, 620 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы территориясендә «Туризмны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе территориясе буенча туристлык сәяхәтләре саны»

күрсәткеченә ирешү белән бәйле аларның чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«проект – Татарстан Республикасы территориясендә туризм инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән, сайлап алуда катнашучының сорала торган субсидия күләменнән кимендә 50 процент күләмендә акчасы һәм субсидия акчасы кебек финанслау чыганакларыннан торган бюджет белән, субсидия бирү максатлары нигезендә гамәлгә ашыру срогы 2026 елның 1 апреленә кадәр (2025 елда субсидия алган сайлап алуда катнашучылар өчен), тиешле финанс елының 20 декабренә кадәр (2026 елда һәм аннан соңгы елларда субсидия алган сайлап алуда катнашучылар өчен) булган оештыру-технологик документ рәвешендәге эшмәкәрлек инициативасы (бу төшенчә әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявкага карата кулланыла).»;

4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

44 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«44. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган тарафыннан, сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) билгеләнгәннән соң 20 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) белән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешү төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза куела.

Вәкаләтле органга элегрәк җиткерелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт кертелә.

Килешүгә түбәндәгеләр кертелә:

субсидия алучының, субсидияләр алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы;

субсидия алучылар өчен чит ил дәүләтләреннән чыккан (шул исәптән эшләр башкарганда, хезмәтләр күрсәткәндә кайтартыла торган) товарларны, шулай ук чит ил гражданнары, чит ил юридик затлары тарафыннан башкарыла торган эшләрне, күрсәтелә торган хезмәтләрне сатып алуны чикләү һәм (яки) тыю турында шарт.

Әлеге шартларны билгеләү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Вәкаләтле орган, кирәк булганда, субсидия алучы белән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

53 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент счетларына» сүзләрен «счетка» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин